СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

31.03.2025 № 56/6

На №__________ от______________

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә маневрлы торак фонды турында» тәртипне раслау хакында**

Россия Федерациясе Гражданнар кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 январендагы 42 номерлы карары белән расланган Торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләре һәм маневрлы фондның торак урынын наемга алу типлаштырылган шартнамәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 январендагы 25 номерлы карары белән расланган Торак урыннардан файдалану кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ**:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә маневрлы торак фонды турында» тәртипне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районы Советының 31 мартындагы ___ номерлы карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә маневрлы торак фонды турында тәртип

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 январендагы 42 номерлы карары белән расланган Торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләре һәм маневрлы фондның торак урынын наемга алу типлаштырылган шартнамәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 январендагы 25 номерлы карары белән расланган торак урыннардан файдалану кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге тәртип, билгеле бер төргә, атап әйткәндә, маневрлы фондның торак урыннарына кертеп, торак урынны күрсәтелгән фондтан төшереп калдыру тәртибен билгели, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы милкендәге һәм муниципаль торак фондын тәшкил итүче маневр фондының торак урыннарын аерым категория гражданнарга бирү һәм алардан файдалану тәртибен билгели.

1.3. Муниципаль маневрлы торак фонды (алга таба - маневрлы фонд) - гамәлдәге законнарда каралган очракларда вакытлыча яшәү өчен билгеләнгән махсуслаштырылган муниципаль торак фонды төре:

1.3.1. Социаль наем шартнамәләре буенча биләгән торак урыннары булган гражданнарга йортны капиталь ремонтлауга яисә реконструкцияләүгә бәйле рәвештә.

1.3.2. Банк яки башка кредит оешмасы кредиты яисә юридик зат тарафыннан торак урын сатып алу өчен бирелгән максатчан заем акчалары хисабына сатып алынган һәм, әгәр түләтү мөрәҗәгате кергәндә мондый торак урыннар алар өчен бердәнбер булса, кредитны яисә максатчан заемны кире кайтаруны тәэмин итүгә салынган әлеге торак урыннарга түләтү мөрәҗәгате нәтиҗәсендә торак урыннарын югалткан гражданнарга.

1.3.3. Бердәнбер торак биналары гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксыз булган гражданнарга.

1.3.4. Законнарда каралган очракларда башка гражданнарга.

1.4. Маневрлы фонд күпфатирлы йортлардан, шулай ук гражданнар яшәү өчен яраклы (билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, экологик һәм законнарның башка таләпләренә җавап бирергә), урнашкан торак пункт шартларына карата төзекләндерелгән булырга тиешле фатирлардан һәм башка торак биналардан төзелә.

1.5. Маневрлы фондның торак биналары хосусыйлаштырылырга, алмаштырылырга, читләштерелергә, арендага, поднаемга тапшырылырга тиеш түгел.

1.6. Маневрлы фондның торак урыннарын исәпкә алу Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.7. Маневрлы фондның торак урыннарына урнаштырылучы гражданнарны теркәү Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 2. Маневрлы торак фондын булдыру тәртибе

2.1. Маневрлы муниципаль торак фондының торак урыннары реестры Татарстан

Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

2.2. Торак урынны маневрлы фондка кертү һәм күрсәтелгән фондтан төшереп калдыру, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26.01.2006 ел, № 42 карары белән расланган Торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртип һәм таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла, мондый торак урыннарны бирү Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетның торак комиссиясе карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.3. Маневрлы торак фонды түбәндәгеләр хисабына формалаша:

1) муниципаль берәмлекнең муниципаль торак фондының бушаган торак урыннары;

2) Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә торак урыннар төзү, реконструкцияләү яки торак урыннар сатып алу.

### 3. Маневрлы торак урын бирү нигезләре, шартлары һәм срогы

3.1. Маневрлы фондның торак биналары бер кешегә кимендә алты квадрат метр торак мәйданы исәбеннән бирелә.

3.2. Маневрлы фондның торак урынга наем шартнамәсе (маневрлы фондның торак урынга наем шартнамәсе формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26.01.2006 № 42 карары белән расланган, 1 кушымта) түбәндәге чорга төзелә:

- күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау яки реконструкцияләү тәмамланганчы;
- бу урынга түләтү мөрәҗәгате нәтиҗәсендә торак урынын югалткан яллаучы белән исәп-хисаплар тәмамланганчы;
- гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын өчен яллаучы белән исәп-хисаплар тәмамланганчы;
- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка срокка.

3.3. Маневрлы фондның торак урынын наемга алу шартнамәсе төзелгән срокның тәмамлануы әлеге шартнамәне туктатуга нигез булып тора.

3.4. Маневрлы фондның торак урынына наем шартнамәсенең гамәлдә булу вакыты, нигезләнгән сәбәпләр булганда, торак комиссиясе карары нигезендә озайтылырга мөмкин.

### 4. Маневрлы фондның торак урынына наем шартнамәсе буенча торак урыннар бирү тәртибе

4.1. Исәпкә кую һәм маневрлы фондның торак урынын наемга алу шартнамәсе буенча маневрлы фондның торак урынын бирү турында мәсьәләне карау өчен, гражданнарга Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

1) гаиләнең барлык балигъ булган әгъзалары имзалаган шәхси гариза (2 кушымта);

2) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документлар (паспорт яки аны алыштыручы башка документ);

3) мөрәҗәгать итүче һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документлар;

4) әлеге Тәртипнең 1.3 пункты нигезендә маневрлы фондның торак урын бирү шартларын раслаучы документлар.

Исәпкә кую (маневр фондының торак урыны бирү) турында гариза биргән гражданга документларны алуга расписка бирелә.

4.2. Мөрәҗәгать итүчене исәпкә кую яисә маневрлы фондның торак урынына

мохтаҗ буларак исәпкә алудан баш тарту турында мәсьәлә торак комиссиясе тарафыннан карала.

4.3. Торак комиссиясенең маневрлы фондның торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую һәм гражданга маневрлы фондның торак урынын бирү турында карары документлар тапшырылганнан соң иң кыска вакыт эчендә, әмма 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

4.4. Маневрлы фондның торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алудан баш тарту турында торак комиссиясе карары түбәндәге очракларда кабул ителә, әгәр:

- әлеге Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә тиешле гражданнарның маневрлы фондның торак урынын бирү хокукын расламаган документлар тапшырылды.

4.5. Гражданнарга маневрлы фондның торак урыннары бирү торак комиссиясе карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.6. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының гражданнарга маневрлы фондның торак урыннарын бирүне тәкъдим итү турында карары нигезендә Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге тарафыннан маневрлы фондның торак урынын наемга алу шартнамәсе төзелә.

4.7. Маневрлы фондның торак урынын наемга алу шартнамәсе Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китереп язма рәвештә төзелә һәм маневрлы фондның торак урынына урнаштыру өчен бердәнбер нигез булып тора.

## 5. Маневрлы фондның наем шартнамәсе буенча торак урыннан файдалану

5.1. Маневрлы фондның торак урыннарыннан файдалану, аларны карап тоту һәм анда яшәүче гражданнарга торак коммуналь хезмәтләре күрсәтү тәртибе түбәндәгечә регламенттала: Россия Торак кодексының 17 статьясы 4 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 21.01.2006 № 25 карары белән расланган Торак урыннардан файдалану кагыйдәләре һәм маневрлы фондның торак урыннарына наем шартнамәсе.

5.2. Яллаучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары маневрлы фондның торак урыннарыннан бары тик яшәү өчен генә файдаланырга, торак урынның сакланышын тәэмин итәргә һәм аны тиешле хәлдә тотарга тиеш.

5.3. Бер бүлмәдән (фатирдан) икенчесенә үз белдегең белән күчү, шулай ук маневрлы фондның торак урынына наем шартнамәсенә кертелмәгән затларны урнаштыру рөхсәт ителми.

5.4. Гражданнар маневрлы фондның торак урынына күчерелгәндә, даими яшәү урыны буенча социаль наем шартнамәсе өзелми, шул ук вакытта гражданнар әлеге шартнамә буенча бурычларын үтәүдән аларны күчергән вакыттан алып элеккеге яшәү урынына кире күчерелгән яки башка торак урын бирелгән вакытка кадәр азат ителәләр.

5.5. Маневрлы фондның торак урынын наемга алу шартнамәсе торак законнарында каралган нигезләрдә туктатылган яки өзелгән очракта, әлеге торак урыннарны биләүче гражданнар аларны маневрлы фондның торак урынын наемга алу шартнамәсендә билгеләнгән срокта азат итәргә тиеш.

## 6. Маневрлы фондның торак урыныннан файдаланган өчен түләү

6.1. Маневрлы фондның торак биналарына күчкән гражданнар РФ законнары һәм наем шартнамәсе нигезендә билгеләнгән тәртиптә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертергә тиеш.

6.2. Маневрлы фондта яшәүче гражданнар өчен торак урыны һәм коммуналь

хезмәтләр өчен түләү күләме гамәлдәге бәяләр һәм тарифлар буенча билгеләнә һәм муниципаль торак фондын яллаучылар өчен яшәү өчен түләү күләменнән арта алмый.

## 7. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Маневрлы фондның торак урыннардан файдалану кагыйдәләрен системалы рәвештә бозучы, аны тиешенчә файдаланмаучы яки үз-үзләрен тотышы белән алар белән бер фатирда, бер йортта яшәү өчен мөмкин булмаган шартлар тудыручы торак урынын яллаучы һәм аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары РФ Торак кодексының 101 статьясы һәм РФ ГК 687 статьясы нигезендә суд тәртибендә чыгарылырга мөмкин.

7.2. Әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган мәсьәләләр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә хәл ителә.